| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>АГРЫЗСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2020 Әгерҗе шәһәре № 3-7

«Әгерҗе муниципаль районында аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2020 елның 29 маендагы 47-14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.04.2020 № 821-р күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 06 августындагы 1497-р номерлы күрсәтмәсе, «Арендаторларга ярдәм чаралары күрсәтү буенча норматив актларга үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының 19.08.2020 № 1-31/10318 йөкләмәсе нигезендә, муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, аны Россия Федерациясе законнарына һәм норматив хокукый актларга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Әгерҗе муниципаль районында аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 29 маендагы 47-14 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктта «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) арендалаучылар мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде эш көне эчендә - кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар-иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручылар реестрына кертелгән, Россия икътисады тармаклары исемлеге буенча бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып баручы коммерциячел булмаган оешмалар реестрына кертелгән, яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча өстәмә килешүләр төзү,

2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 октябренә кадәр аренда түләүләрен кичектереп торуны күздә тота торган өстәмә килешүләр төзү.

Арендатор икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә, алар турында мәгълүмат юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында йә индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә торышы буенча бирелә.

Өстәмә килешүләр Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендага бирү шартнамәләренә, аны икътисадый эшчәнлекнең күрсәтелгән төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдалану максатларында һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәттән файдалануны раслый торган документлар булган очракта, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага арендаторлар белән, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы муниципаль районының муниципаль казнасын (шул исәптән җир участокларын) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләре башкарылмаган вакытта арендалау буенча күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдалануны раслый торган документлар булган очракта төзелә..»;

- «б» пунктчасында «кече һәм урта эшкуарлык субъектлары» сүзләреннән соң «социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләрен өстәргә»;

- 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән арендаторлар белән өстәмә килешүләр түбәндәге шартларда төзелә:

– аренда түләве буенча бурыч арендаторлар тарафыннан тәкъдим ителгән срокта 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да ешрак түләнергә тиеш, аларның күләме аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмый;
– кичектереп торуга бәйле рәвештә штрафлар, чит акчалардан файдаланган өчен процентлар яисә арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле рәвештә башка җаваплылык чаралары кулланылмый (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда да);
– кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;
– аренда шартнамәсе вакытыннан алда өзелгәндә аренда түләве буенча бурыч бер мәртәбә түләнә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев